ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12; 2013, № 5, № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2015, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2016, № 11; 2017, № 7, № 12; 2018, № 12; 2019, № 7 – 8; 2020, № 4; 2021, № 1 – 2, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча докладларның дәвамлылыгы, доклад ясаучылар белән килешенеп, Дәүләт Советы Президиумы утырышында рәислек итүче тарафыннан билгеләнә, әмма ул вакыт 15 минуттан артмаска тиеш. Дәүләт Советы Президиумы әгъзалары, дәүләт сере һәм законнар белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен истә тотып, докладчыга сораулар бирергә хокуклы. Сорауның дәвамлылыгы – бер минуттан, җавап бирү өч минуттан артмаска тиеш. Сораулар һәм сорауларга җаваплар бирү өчен гомуми вакыт 10 минуттан артмаска тиеш. Билгеләнгән вакыт узганнан соң рәислек итүче бу турыда чыгыш ясаучыны кисәтә, ә аннан соң чыгышын туктатырга хокуклы.»;

2) 46 статьяның 4 өлешендә «санлы» сүзен төшереп калдырырга;

3) 193 статьяның 2 өлешендә «каралалар» сүзен «каралырга мөмкин» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 219-VII ДС